ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 922 2016 елның 23 мае

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 26 гыйнварындагы 102 номерлы карары белән расланган «Түбән Кама муниципаль районының 2015-2020 елларга коррупциягә каршы комплекслы программа»сына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының «2016-2017 елларга коррупциягә каршы торуның милли планы турында» 2016 елның 1 апрелендәге 147 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның 2016 елның 1 апрелендәге 18277-МР номерлы күрсәтмәсе нигезендә, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 26 гыйнварындагы 102 номерлы карары белән расланган «2015-2020 елларга Түбән Кама муниципаль районының коррупциягә каршы комплекслы программасы»на, 1.18.1. пунктын өстәргә:

«1.18.1. Түбән Кама муниципаль районы территориясендә, урманнарны һәм су саклау зоналарын законсыз файдалану һәм төзүгә бәйле хокук бозуларны ачыклауга халыкны җәлеп итү максатыннан, «Халык инвентаризациясе» акциясен үткәрү. Ачыкланган бозуларны кисәтү, аларның нәтиҗәләрен бетерү өчен чаралар күрергә.».

Үтәү срогы: 2016-2017 еллар.

Үтәү өчен җаваплы: Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре идарәсе, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының әйләнә-тирә мохитне саклау бүлеге, Түбән Кама шәһәр прокуратурасы (килешү буенча).

2. Әлеге карар кул куелганнан соң үз көченә керә.

3. Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче В.В. Федотов